РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«29» декабря 2022г. с. Тюлячи № 293

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 31 гыйнварындагы 40 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору, Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану һәм 2023 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2022 елның 21 ноябрендәге 448-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 31 гыйнварындагы 40 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында» карарына (19.03.2012 № 288, 16.05.2017 № 243 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибенә:

А) 1.2 пунктта «һәм Теләче муниципаль районы бюджетының расланган чыгымнарының өч процентыннан артмаска тиеш» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Җитәкче урынбасары – Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы Б.Г. Гайнетдиновка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Ф.С. Вәлеев